ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.06.2026 п.г.т. Алексеевское № 56

**«Алексеевск үзәк район хастаханәсе» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасының «Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта кул медицина хезмәткәре», «Фельдшер-акушерлык пунктының иң яхшы медицина хезмәткәре» муниципаль грантларын бирү турындагы Нигезләмәләрне раслау хакында**

Һөнәри камилләшүгә, нәтиҗәле хезмәткә, сәламәтлек саклау белгечләре өчен аны рациональ оештыруга өстәмә стимуллар булдыру, медицина хезмәткәренең абруен, дәрәҗәсен, иҗтимагый әһәмиятен күтәрү максатында,

**карар бирәм:**

1. «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасының «Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта кул медицина хезмәткәре», «Фельдшер-акушерлык пунктының иң яхшы медицина хезмәткәре» муниципаль грантларын бирү турындагы Нигезләмәләрне расларга. (Кушымта №1, №2, №3).

2. Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасында «Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта кул медицина хезмәткәре», «Фельдшер-акушерлык пунктының иң яхшы медицина хезмәткәре» муниципаль грантларын алуга дәгъва итүчеләрне сайлап алу комиссиясе составын (4 нче кушымта) расларга.

3. Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасына (Мифтахова Е.М.) приз фонды сыйфатында 130 000 сум күләмендә акча бүлеп бирергә.

4. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 06.06.2019 ел, №28 «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасының «Иң яхшы табиб»,«Иң яхшы урта кул медицина хезмәткәре», «Фельдшер-акушерлык пунктының иң яхшы медицина хезмәткәре» муниципаль грантларын бирү турындагы Нигезләмәләрне раслау хакында» карары, «Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 06.06.2019 ел, №28 «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасының «Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта кул медицина хезмәткәре»,«Фельдшер-акушерлык пунктының иң яхшы медицина хезмәткәре» муниципаль грантларын бирү турындагы Нигезләмәләрне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү

турында»15.06.2020 ел, № 65, 04.12.2020 ел, № 90 карары үз көчен югалткан дип санарга.

5. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммукация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә (Леденцов О. Н.), Алексеевск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы Рәисенә (Мифтахова Е. М.) йөкләргә.

**Муниципаль район**
**Башлыгы** **С. А. Демидов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башлыгының
15.06.2026 ел, № 56
карарына 1 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасының «Иң яхшы табибы» муниципаль грантын бирү турындагы**
**Нигезләмә**

**Максат**: Һөнәри камилләшүгә, нәтиҗәле хезмәткә, аны рациональ оештыруга өстәмә стимул тудыру. Табибның абруен, дәрәҗәсен, иҗтимагый әһәмиятен күтәрү.

**Бурычлар**: Җиңүчеләрне югары һөнәри осталык һәм эшне рациональ оештырган өчен бүләкләү. Иң яхшы белгечләрнең казанышларын, аларның тармакта, район халкы арасында алдынгы тәҗрибәләрен пропагандалау, медицина хезмәткәренең имиджын, аның хезмәтенең җаваплылыгын һәм әһәмиятен формалаштыру.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алексеевск муниципаль районы Башлыгы гранты белән «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» «ДАССОның иң яхшы табибы» югары һөнәри осталыгы һәм Алексеевск районында сәламәтлек саклауга керткән зур өлеше өчен бүләкләнә.

1.2. Ел саен «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОның «Иң яхшы табиб» номинациясе буенча район Башлыгы гранты 50.0 мең сум күләмендә түләнә. Конкурста барлык белгечлек табиблары да катнаша ала.

1.3. Район Башлыгы гранты конкурс буенча сайлап алынган табибка түләнә.

1.4. Табиб белгечлеге буенча эш стажы 5 елдан да иртәрәк булмаган вакытта район Башлыгы грантын кабат алырга хокуклы.

1.5. Район Башлыгы грантын бирү өчен табибны конкурста сайлап алу тәртибе һәм критерийлары әлеге Нигезләмәдә билгеләнә.

1.6. Район Башлыгы гранты Алексеевск районы бюджетында бүлеп бирелгән максатчан финанс средстволарыннан түләнә һәм табиб кадрларының һөнәри үсешен һәм квалификациясен стимуллаштыру өчен каралган.

1.7. Түләү планлаштырылган айга кадәрге айның беренче числосына район Башлыгы грантын алучылар туры килергә тиешле таләпләр:

- Район Башлыгы грантын алучыларның салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

- Район Башлыгы грантын алучының әлеге тәртип нигезендә грант бирү планлаштырылган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы

бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, субсидияләр, башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләре һәм Алексеевск муниципаль районы бюджеты алдында бүтән срогы чыккан бурычы булмаска тиеш.

## 2. Конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары

Иң яхшы табибны конкурс нигезендә сайлап алу ике төркем критерийлар: квалификацион сайлап алу критерийлары һәм конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Катнашу һәм сайлап алу критерийлары фиксацияләнгән һәм мәҗбүри.

2.1. Катнашу критерийлары:

- табибның белгеч сертификаты бар;
- табиб беренче яки югары квалификация категориясенә ия;
- хезмәт эшчәнлегенә характеристика;
- табибның «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОда 3 елдан да ким булмаган эш стажы.

2.2. Сайлап алу критерийлары:

2.2.1: сыйфат параметрлары 10 баллы шкала буенча бәяләнә:

- соңгы өч ел дәвамында статистик күрсәткечләр динамикасын чагылдырган һөнәри эшчәнлекнең төп йомгаклары турында белешмәләр-5балл;
- соңгы өч ел дәвамында конкурсант тарафыннан (яисә аның турыдан-туры катнашында) профилактикалауның, диагностикалауның һәм дәвалауның яңа ысулларын эшләү яисә гамәлгә кертү -2 балл;
- профилактик эш, халыкны гигиенага өйрәтү һәм тәрбияләү, массакүләм мәгълүмат чараларында чыгышлар, язмалар булу-2 балл;
- җәмәгатьчелек бәясе, пациентларның табиб турында фикере - 1 балл.

## 3. Конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру тәртибе

3.1. Иң яхшы табибны конкурс нигезендә сайлап алу максатында конкурс комиссиясе раслана.

3.2. Конкурста катнашу өчен кандидатлар Комиссия рәисе исеменә гариза җибәрәләр.

3.3. Конкурста катнашуга гариза агымдагы елның 1 июненнән дә соңга калмыйча бирелергә тиеш.

3.4. Грант алуга гаризаның титул кәгазе үз эченә алырга тиеш:

-врачның фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- конкурс номинациясе;
- гариза бирү датасы;
-врач имзасы.

3.5. Документлар муниципаль конкурс комиссиясенә исемлек нигезендә тапшырыла:

- конкурста катнашу өчен Комиссия рәисе исеменә гариза;
- белем турындагы дипломның күчермәсе;
- сертификат күчермәсе;
- категория турында таныклык күчермәсе;

- хезмәт кенәгәсенең күчермәсе;

- соңгы өч елдагы эшчәнлеккә анализ әлеге Нигезләмәнең 2.2 пункты нигезендә.

- булган бүләкләр һәм бүләкләүләр.

Документлар карау һәм күрсәтмәлелек уңайлылыгы өчен файллар белән папкага җыелырга тиеш.

## 4. Конкурста җиңүчене сайлап алу

4.1. Конкурста җиңүчене сайлап алуны уздыру Комиссия компетенциясенә керә.

4.2. Сайлау критерийлары буенча дәгъвачы документлары пакетын теркәү һәм техник экспертизаны Комиссия агымдагы елның 1 июненә кадәр уздыра.

4.3. Комиссия карары буенча табиб эшчәнлегенә эксперт бәясе аның эш урынына барып бәяләнергә мөмкин.

4.4. Үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре нигезендә Комиссия дәгъвачылар рейтингын төзи, район Башлыгы грантын алучыны билгели, беркетмә төзи һәм карау нәтиҗәләрен Алексеевск муниципаль районы Башлыгына тапшыра.

4.5. Грант бирү турындагы карар Алексеевск муниципаль районы Башлыгы карары белән рәсмиләштерелә.

4.6. «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Иң яхшы табибы» грантын Алексеевск муниципаль районы Башлыгы ел саен июнь аенда медицина хезмәткәре көненә багышланган тантаналы утырышта тапшыра.

4.7. Конкурс нәтиҗәләре мәгълүмати хатлар, басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет-сайтлар һ. б. аша мәҗбүри рәвештә киң җәмәгатьчелеккә җиткерелә.

**Советның Аппарат Җитәкчесе** **И. Ю. Монина**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башлыгының
15.06.2026 ел, № 56
карарына 2 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасының «Иң яхшы урта кул медицина хезмәткәре» муниципаль грантын бирү турындагы Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алексеевск муниципаль районы Башлыгы гранты белән югары һөнәри осталыгы һәм сәламәтлек саклауга зур өлеш керткәне өчен «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасының иң яхшы урта кул медицина хезмәткәре бүләкләнә.

1.2. Ел саен район Башлыгының 40.0 мең сум күләмендә 1 гранты түләнә.

1.3. Район Башлыгы гранты муниципаль сәламәтлек саклау оешмасының конкурс нигезендә сайлап алынган урта кул медицина хезмәткәренә түләнә.

1.4. Урта кул медицина хезмәткәре район Башлыгы грантын 5 елдан да иртәрәк алмыйча кабаттан алырга хокуклы.

1.5. Район Башлыгы грантларын бирү өчен урта кул медицина хезмәткәрләрен конкурста сайлап алу тәртибе һәм критерийлары әлеге нигезләмәдә билгеләнә.

1.6. Район Башлыгы гранты Алексеевск муниципаль районы бюджетында бүлеп бирелгән максатчан финанс средстволарыннан түләнә һәм урта кул медицина хезмәткәрләре һөнәренең һөнәри үсешен, квалификациясен һәм абруен стимуллаштыру өчен билгеләнә.

1.7. Түләү планлаштырылган айга кадәрге айның беренче числосына район Башлыгы грантын алучылар туры килергә тиешле таләпләр:

- район Башлыгы грантын алучыларның салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;
- район Башлыгы грантын алучының әлеге тәртип нигезендә грант бирү планлаштырылган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, субсидияләр, башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләре һәм Алексеевск муниципаль районы бюджеты алдында бүтән срогы чыккан бурычы булмаска тиеш.

## 2. Конкурсны уздыру шартлары һәм тәртибе

2.1. Конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру максатында конкурс комиссиясе раслана.

2.2. Конкурста «Шәфкать туташы эше», «Дәвалау эше» һәм «Акушерлык эше» белгечлекләре буенча урта медицина белеме булган, белгечлек сертификатлары, беренче яки югары квалификация категориясе булган һәм белгечлеге буенча «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОда кимендә 3 ел эш стажы булган белгечләр катнаша ала.

2.3. Конкурска кандидатуралар «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Иң яхшы урта кул медицина хезмәткәре» исеменә дәгъва кылучыларның һөнәри, иҗади, әхлакый сыйфатларыннан чыгып, «Алексеевск үзәк район хастаханәсе»ДАССОның аерым бүлекчәләре коллективлары тарафыннан күрсәтелә.

2.4. Дәгъвачыга документлар гариза бирүче тарафыннан муниципаль конкурс комиссиясенә исемлек нигезендә агымдагы елның 1 июненнән дә соңга калмыйча тапшырыла:

- конкурс комиссиясе рәисе исеменә конкурста катнашуга гариза;
- белем турындагы дипломның күчермәсе;
- сертификат күчермәсе;
- категория турында таныклык күчермәсе;
-хезмәт кенәгәсенең күчермәсе.

2.5. Конкурста катнашуга гаризаның титул бите үз эченә алырга тиеш:

- аерымланган бүлекчәнең исеме;
- урта кул медицина хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- конкурс номинациясе;
- гариза бирү датасы;
-баш врачның имзасы.

2.6. Конкурсны үткәрү датасын комиссия билгели.

2.7. Сайлап алу критерийлары 10 баллы шкала буенча бәяләнә:

- конкурста катнашучының һөнәри эшчәнлегенең төп йомгаклары, медицина технологияләрен белүе турында соңгы өч ел дәвамында статистик күрсәткечләр динамикасын чагылдырган хисабы-5 балл;
- конкурста катнашучының эшен тасвирлаучы фото-видеоматериаллар-2 балл;
- профилактик эш, халыкны гигиенага өйрәтү һәм тәрбияләү, массакүләм мәгълүмат чараларында чыгышлар, язмалар булу-2 балл;
- җәмәгать бәясе, пациентларның конкурста катнашучы турында бәяләмәләре - 1 балл.

Әгәр ике һәм аннан күбрәк конкурсант бертигез балл җыйса, аларга конкурста җиңүчене төгәл билгеләү максатында өстәмә теоретик яисә практик биремнәр тәкъдим ителә.

2.8. Үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре нигезендә комиссия дәгъвачылар рейтингын төзи һәм район Башлыгы грантын алучыны билгели, беркетмә төзи һәм карау нәтиҗәләрен Алексеевск муниципаль районы Башлыгына тапшыра.

2.9. Район Башлыгы грантын бирү турындагы карар Алексеевск муниципаль районы Башлыгы карары белән рәсмиләштерелә.

2.10. Район Башлыгы грантына лаек булган урта кул медицина хезмәткәрләрен бүләкләү Алексеевск муниципаль районы Башлыгы

тарафыннан ел саен июнь аенда медицина хезмәткәре көненә багышланган тантаналы утырышта гамәлгә ашырыла.

2.11. Конкурс нәтиҗәләре мәгълүмати хатлар, басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет-сайтлар һ. б. аша мәҗбүри рәвештә киң җәмәгатьчелеккә җиткерелә.

**Советның Аппарат Җитәкчесе** **И. Ю. Монина**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башлыгының
15.06.2026 ел, № 56
карарына 3 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасының «Фельдшер-акушерлык пунктының иң яхшы медицина хезмәткәре» муниципаль грантын бирү турындагы**
**Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Алексеевск муниципаль районы Башлыгы гранты белән «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе фельдшер-акушерлык пунктының иң яхшы медицина хезмәткәре югары һөнәри осталыгы һәм Алексеевск муниципаль районы сәламәтлек саклауга зур өлеш керткәне өчен бүләкләнә.

1.2. Ел саен район Башлыгының 40 мең сум күләмендә 1 гранты түләнә.

1.3. Район Башлыгының гранты конкурс нигезендә сайлап алынган фельдшер-акушерлык пунктларының медицина хезмәткәренә түләнә.

1.4. ФАПның медицина хезмәткәре район Башлыгы грантын кимендә 5 елдан соң кабат алырга хокуклы.

1.5. Район Башлыгының грантын бирү өчен ФАП медицина хезмәткәрен конкурста сайлап алу тәртибе һәм критерийлары әлеге нигезләмәдә билгеләнә.

1.6. район Башлыгының гранты Алексеевск муниципаль районы бюджетында бүлеп бирелгән максатчан финанс средстволарыннан түләнә һәм медицина хезмәткәре һөнәренең һөнәри үсешен, квалификациясен һәм абруен стимуллаштыру өчен билгеләнә.

1.7. Түләү планлаштырылган айга кадәрге айның беренче числосына район Башлыгының грантын алучылар туры килергә тиешле таләпләр:

- башлык грантын алучыларның салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

- район Башлыгының грантын алучының әлеге тәртип нигезендә грант бирү планлаштырылган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, субсидияләр, башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләре һәм Алексеевск муниципаль районы бюджеты алдында бүтән срогы чыккан бурычы булмаска тиеш.

## 2. Конкурсны уздыру шартлары һәм тәртибе

2.1. Конкурс нигезендә сайлап алуны уздыру максатында конкурс комиссиясе раслана.

2.2. Конкурста катнашуга «Шәфкать туташы эше», «Дәвалау эше» һәм «Акушерлык эше» белгечлекләре буенча урта медицина белеме булган, фельдшер-акушерлык пунктларында эшләүче, белгечлек сертификатлары, беренче яисә югары квалификация категориясе булган һәм белгечлеге буенча «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОда кимендә 3 ел эш стажы булган белгечләр кертелә.

2.3. Конкурска кандидатуралар «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең «Иң яхшы ФАП медицина хезмәткәре» исеменә дәгъва кылучыларның һөнәри, иҗади, әхлакый сыйфатларыннан чыгып күрсәтелә.

2.4. Дәгъвачыга документлар гаризачы тарафыннан муниципаль комиссиягә исемлек нигезендә агымдагы елның 1 июненнән дә соңга калмыйча тапшырыла:

- конкурс комиссиясе рәисе исеменә конкурста катнашуга гариза;
- белем турындагы дипломның күчермәсе;
- сертификат күчермәсе;
- категория турында таныклык күчермәсе;
-хезмәт кенәгәсенең күчермәсе.

2.5. Конкурста катнашуга гаризаның титул бите үз эченә алырга тиеш:

- аерымланган бүлекчәнең исеме;
- урта кул медицина хезмәткәренең фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- конкурс номинациясе;
- гариза бирү датасы;
-баш врачның имзасы.

2.6. Конкурсны үткәрү датасын Комиссия билгели.

2.7. Сайлап алу критерийлары 10 баллы шкала буенча бәяләнә:

- конкурста катнашучының һөнәри эшчәнлегенең төп йомгаклары, медицина технологияләрен белүе турында соңгы өч ел дәвамында статистик күрсәткечләр динамикасын чагылдырган хисабы-5 балл;
- конкурста катнашучының эшен тасвирлаучы фото-видеоматериаллар-2 балл;
- профилактик эш, халыкны гигиенага өйрәтү һәм тәрбияләү, массакүләм мәгълүмат чараларында чыгышлар, язмалар булу-2 балл;
- җәмәгать бәясе, пациентларның конкурста катнашучы турында бәяләмәләре - 1 балл.

Әгәр ике һәм аннан күбрәк конкурсант бертигез балл җыйса, аларга конкурста җиңүчене төгәл билгеләү максатында өстәмә теоретик яисә практик биремнәр тәкъдим ителә.

2.8. Үткәрелгән конкурс нәтиҗәләре нигезендә комиссия дәгъвачылар рейтингын төзи һәм район Башлыгы грантын алучыны билгели, беркетмә төзи һәм карау нәтиҗәләрен Алексеевск муниципаль районы Башлыгына тапшыра.

2.9. Район Башлыгы грантын бирү турындагы карар Алексеевск муниципаль районы Башлыгы карары белән рәсмиләштерелә.

2.10. Район Башлыгы грантына лаек булган медицина хезмәткәрен бүләкләү Алексеевск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан июнь аенда медицина хезмәткәре көненә багышланган тантаналы утырышта башкарыла.

2.11. Конкурс нәтиҗәләре мәгълүмати хатлар, басма һәм электрон массакүләм мәгълүмат чаралары, интернет-сайтлар һ. б. аша мәҗбүри рәвештә киң җәмәгатьчелеккә җиткерелә.

**Советның Аппарат**
**Җитәкчесе** **И. Ю. Монина**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башлыгының
15.06.2026 ел, № 56
карарына 4 нче кушымта

**Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» Дәүләт автоном сәламәтлек саклау оешмасында «Иң яхшы табиб», «Иң яхшы урта кул медицина хезмәткәре», «Фельдшер-акушерлык пунктының иң яхшы медицина хезмәткәре» муниципаль грантларын алуга дәгъва итүчеләрне сайлап алу комиссиясе**
**Составы**

| | |
|---|---|
| 1. Леденцов О.Н. | - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| 2. Мостафин Р.Р. | - «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОныц баш табибы, комиссия рәисе урынбасары |
| 3. Фәссахова А.Р. | - утратавыш диагностикасы табибы, баш табибның дәвалау эше буенча урынбасары вазыйфаларын башкаручы |
| 4. Аляшева И.Г. | -«Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОның баш шәфкать туташы |
| 5. Гордеева Т.Г. | -ГМК өлкән фельдшеры-комиссия секретаре |
| 6. Вәлиева З.Н. | -«Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОның профком рәисе |
| 7. Турсен Т.А. | - «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССОның кадрлар бүлеге белгече. |

**Советның Аппарат Җитәкчесе** **И. Ю. Монина**